

УЕ ИЗГЕ: БАЛАСЫНА
БУЛЫШЫР ТАБИГАТЬ ТӘ.
ЭШКӘ ТОТЫНЫЙК, ДУСЛАРЫМ,
ХУШ, ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ.



1. Әлеге фигыль нинди сорауларга җавап бирә?
2. Нинди мәгънә белдерә?
3. Нинди кушымчалар ала?
4. Барлыкта – юклыкта киләме?
5. Зат-сан белән төрләнәме?

1. Әлеге фигыль нинди сорауларга җавап бирә?
2. Нинди мәгънә белдерә?
3. Нинди кушымчалар ала?
4. Барлыкта – юклыкта киләме?
5. Зат-сан белән төрләнәме?



Нишләсә?


- Кояш болытка капланып баеса, яңгыр явар.
- Кар калын булса, ашлык уңар.
- Томан җиргә төшсә, аяз булыр.
- Елга суы боз өстенә чыкса, көн җылытыр.
- Март башында тамчы тамса, җәй яхшы килә.
- Каен суы күп акса, җәй яңгы



# Шарт фигыль кушымчасы : -са / -сә

баеса
чыкса
янса
тамса
акса

өзсә
китсә
тисә
үссә
сипсә




# Шарт фигыльнең барлыкта һәм юклыкта төрләнүе

| Барлыкта Нишләсә? | | Юклыкта Нишләмәсә? | |
|---|---|---|---|
| -са/-сә | | -ма+са /-мә+сә | |
| баеса | өзсә | баемаса | өзмәсә |
| чыкса | китсә | чыкмаса | китмәсә |
| янса | тисә | янмаса | тимәсә |
| тамса | үссә | таммаса | үсмәсә |
| акса | сипсә | акмаса | сипмәсә |

# Затланышлы фигыльләр

Затланышлы фигыльләр

Затланышсыз фигыльләр



# Шарт фигыль зат-сан белән төрләнә


**Барлыкта**

**Мин тисә-м**
**Без тисә-к**
**Син тисә-ң**
**Сез тисә-гез**
**Ул тисә**
**Алар тисә-ләр**

**Юклыкта**

**Мин тимәсә-м**
**Без тимәсә-к**
**Син тимәсә-ң**
**Сез тимәсә-гез**
**Ул тимәсә**
**Алар тимәсә-ләр**

1. Шарт фигыль нинди сорауларга җавап бирә?
2. Нинди мәгънә белдерә?
3. Нинди кушымчалар ала?
4. Барлыкта – юклыкта киләме?
5. Зат-сан белән төрләнәме?



# ЙОМГАКЛАУ

- Шарт фигыль икенче бер фигыльдән аңлашылган эш яки хәлнең үтәлү-үтәлмәвенә шарт булган эшне белдерә.
- Нишләсә, нишләмәсә? сорауларына җавап бирә.
- -са/-сә кушымчасы белән ясала: яуса, сипсә.
- Зат-сан белән төрләнә.
- Барлыкта, юклыкта килә.